БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Ленина, д. 42, п.г.т. Балтаси, 422250

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН СОВЕТЫ

Ленин ур., 42 нче йорт, ш.т.п. Балтач, 422250

Тел.: (84368) 2-41-85, факс: (84368) 2-44-50. E-mail: Baltasi.Sovet@tatar.ru, www.baltasi.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** — **КАРАР**

15 март 2019 ел — № 172

## Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә күздә тотылган хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында

“Экологик экспертиза турында” 1995 елның 23 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы Федераль законга, “Әйләнә-тирә мохитне саклау турында” 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль законга, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, “Россия Федерациясендә күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү турындагы нигезләмәне раслау турында” 2000 елның 6 маендагы 372 номерлы РФ Дәүләт Экология комитеты Приказына, Балтач муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балтач район Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә күздә тотылган хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы территориясендә күздә тотылган хуҗалык һәм башка төр эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәнен үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач районы башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Балтач муниципаль район башлыгы,
Балтач район Советы рәисе — Р.Р.Нотфуллин